СОВЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

П.ж.-д.ст.Бурундуки

2016 нче елның 25 январь № 6/3

## Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

15 Федераль законның 12.06.2002г маддәсе нигезендә. «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 67-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Җирле референдум турында» 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының, Яңа Борындык авыл җирлеге Уставының 10 статьясы, «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым турында нигезләмәне раслау һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында» 2014 елның 10 мартындагы 48/1 номерлы Яңа Борындык авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» (үзгәрешләр белән 2014 елның 14 гыйнварындагы 3 номерлы, 12.02.2015 елдагы 85 номерлы), «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2016 елның 25 гыйнварындагы 6/2 номерлы Яңа Борындык авыл җирлеге Советы карары нигезендә, Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгының 2016 елның 23 гыйнварындагы 1 номерлы карары, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1. 2016 елның 13 мартына Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга: «2016 елда үзара салым акчаларын Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җибәрүгә сез риза микән:

-Борындык тимер юл станциясе поселогы Профсоюз урамындагы юлны карап тоту һәм ремонтлау - акчаларны тоту күләме 105900 сум;

“ӘЙЕ» “"ЮК".».

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы:  В.Г. Ранцев